СОВЕТ
ТУКАЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТУКАЙ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

пр. М. Джалиля, 46, г. Набережные Челны, 423800

М. Җәлил пр., 46, Яр Чаллы шәһәре, 423800

Телефон/факс (8552) 70-37-82, tukay@tatar.ru

11.11.2024 № 52/1

На №________ от________

# КАРАР

**«2024-2026 елларга ТР Тукай муниципаль районының юл хәрәкәте иминлеге» комплекслы программасын гамәлгә ашыру турында**

Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесе А.Р. Хәбибуллинның «2024-2026 елларга Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының юл хәрәкәте иминлеге» комплекслы программасын гамәлгә ашыру турында» докладын тыңлап фикер алышканнан соң, муниципаль берәмлек Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. «2024-2026 елларга ТР Тукай муниципаль районының юл хәрәкәте иминлеге» комплекслы программасын гамәлгә ашыру турында» докладны исәпкә алырга.
2. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны бюджет, салымнар, финанс һәм икътисадый сәясәт буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Муниципаль берәмлек Башлыгы
вазифаларын башкаручы,
Совет Рәисе урынбасары

Р.И. Закиров

СОВЕТ
ТУКАЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

пр. М. Джалиля, 46, г. Набережные Челны, 423800

ТУКАЙ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

М. Җәлил пр., 46, Яр Чаллы шәһәре, 423800

Телефон/факс (8552) 70-37-82, tukay@tatar.ru

11.11.2024 № 51/2

На № __________ от ______________

# КАРАР

## Тукай муниципаль районында ветераннарның, өлкән яшьтәге гражданнарның социаль-икътисадый хәлен яхшырту, аларның сәламәтлеген ныгыту һәм актив озак яшәүләренә ярдәм итү турында

Тукай муниципаль районында ветераннарның, өлкән яшьтәге гражданнарның социаль-икътисадый хәлен яхшырту, аларның сәламәтлеген ныгыту һәм актив озак яшәүләренә ярдәм итү турында мәгълүматны тыңлап фикер алышканнан соң, муниципаль берәмлек Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Мәгълүматны исәпкә алырга.
2. Район Башарма комитетына түбәндәге эшләрне дәвам итәргә:

- сугыш һәм хезмәт ветераннарының, пенсионерларның социаль-икътисадый тормыш шартларын яхшырту, аларның социаль яклангнлык дәрәҗәсен арттыру, өлкәннәрнең җәмгыять тормышында катнашуын активлаштыру буенча;
- Бөек Ватан сугышы ветераннарын, пенсионерларны, өлкән яшьтәге кешеләрне юбилей даталары (90 яшьтән башлап) һәм бәйрәм чаралары белән тәбрикләү буенча;
- өлкән яшьтәге гражданнарга медицина хезмәте күрсәтүнең сыйфатын күтәрү буенча эшне көчәйтергә, ташламалы категориядәге гражданнарны дарулар белән тәэмин итү мәсьәләләрен даими контрольдә тотарга;
- район ветераннар (пенсионерлар) советына, җирле үзидарә органнары белән эшләгәндә, тормыш шартларын яхшырту буенча кичектергесез проблемаларны ачыклау өчен, өлкән яшьтәге гражданнар мәнфәгатьләрен актив якларга;
- авыл җирлекләре башлыкларына, календарь һәм истәлекле даталарга багышланган чаралар үткәргәндә, ветераннар, өлкән яшьтәге гражданнарның катнашуын тәэмин итәргә һәм аларны мәдәни-ял һәм массакүләм спорт чараларына актив җәлеп итәргә;
- «Якты юл» («Светлый путь») газетасы редакциясенә ветераннар оешмалары эшчәнлеген, ветераннарның социаль-икътисадый хәле мәсьәләләрен даими яктыртып торырга;
- Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Тукай муниципаль районындагы социаль яклау бүлегенә

өлкән яшьтәге гражданнарны социаль һәм дәвалау-сәламәтләндерү учреждениеләренә җибәрү эшен дәвам итәргә, өлкән яшьтәге гражданнарга адреслы якын килергә;

- ялгыз һәм ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнарга ярдәм күрсәтү өчен, район торак пунктларына мобиль бригада чыгуны системалы рәвештә оештырырга;

- Бердәм дәүләт хезмәтләре порталы аша хезмәтләр алу өчен, өлкән яшьтәге гражданнарны заманча мәгълүмати ресурсларга өйрәтүне дәвам итәргә;

- өлкән яшьтәге гражданнарга адреслы ярдәм күрсәтү өчен, яшьләрнең ирекледәр отрядларын җәлеп итү буенча эшне оештырырга;

- өлкән яшьтәге гражданнарга адреслы ярдәм күрсәтүгә яшьләрнең ирекле отрядларын җәлеп итү буенча эш оештырырга;

- өлкән яшьтәге гражданнар арасында янгын һәм социаль куркынычсызлык чаралары буенча аңлату эшләре алып барырга.

3. Әлеге карарны районның рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны социаль сәясәт, инфраструктура үсеше һәм аграр мәсьәләләр буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Муниципаль берәмлек Башлыгы
вазифаларын башкаручы,
Совет Рәисе урынбасары

Р.И. Закиров

СОВЕТ
ТУКАЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

пр. М. Джалиля, 46, г. Набережные Челны, 423800

ТУКАЙ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

М. Җәлил пр., 46, Яр Чаллы шәһәре, 423800

Телефон/факс (8552) 70-37-82, tukay@tatar.ru

11.11.2024 № 51/3
На №__________от______________

# КАРАР

## 2025 елга һәм 2026, 2027 еллар планы чорына Тукай муниципаль районы бюджет проекты буенча халык тыңлауларын үткәрү турында

«2025 елга һәм 2026, 2027 еллар планы чорына Тукай муниципаль районы бюджеты хакында» Тукай муниципаль районы Советы карары проекты буенча Тукай муниципаль районы халкының фикер алышуда катнашу хокукын саклау максатыннан һәм Тукай муниципаль районында халык тыңлауларын оештыру һәм үткәрү тәртибе турында 2018 елның 29 декабрендәге вн/2 номерлы нигезләмәгә таянып, муниципаль берәмлек Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. «2025 елга һәм 2026, 2027 еллар планы чорына Тукай муниципаль районы бюджеты хакында» карар проекты буенча халык тыңлауларын билгеләргә.

1.1. Халык тыңлауларын үткәрү вакытын 2024 елның 4 декабренә 17.00 сәгатькә билгеләргә, үткәрү урыны: Яр Чаллы шәһәре, М.Җәлил проспекты, 46 йорт (муниципаль район Советының утырышлар залы);

1.2. Фикер алышына торган мәсьәлә буенча тәкъдимнәр һәм чыгыш ясау хокукы белән халык тыңлауларында катнашу өчен гаризалар 2023 елның 2 декабренә кадәр почта аша түбәндәге адреска җибәрелә: 423800, Яр Чаллы шәһәре, М.Җәлил проспекты, 46 йорт, 330 кабинет яисә телефоны буенча юнәлтелә: (8552)701183.

2. «2025 елга һәм 2026, 2027 еллар планы чорына Тукай муниципаль районы бюджеты хакында» карар проекты буенча халык тыңлауларын үткәрү тәртибен кушымта нигезендә расларга.

3. Әлеге карарны һәм «2025 елга һәм 2026, 2027 еллар планы чорына Тукай муниципаль районы бюджеты хакында» карар проектын «Якты юл» («Светлый путь») газетасында бастырырга һәм Тукай районының рәсми сайтында 2024 елның 13 ноябреннән дә соңга калмыйча урнаштырырга.

4. Түбәндәге составта оештыру комитетын төзергә:

- Закиров Рөстәм Илдус улы – район Башлыгы вазифаларын башкаручы,

- Сәхбиев Мансур Шакирҗан улы – бюджет, салымнар һәм икътисадый сәясәт буенча даими комиссия рәисе, Биклән авыл җирлеге Башлыгы,

- Вәлиева Венера Александровна – бюджет, салымнар һәм икътисадый сәясәт буенча даими комиссия әгъзасы, Бәтке авыл җирлеге Башлыгы,

- Хәбибуллин Айрат Рафак улы – район Башкарма комитеты Җитәкчесе,

- Камалова Айгөл Ринат кызы – район финанс-бюджет палатасының әйдәп баручы белгече.

5. Оештыру комитетына билгеләнгән тәртип нигезендә һәм әлеге карарда билгеләнгән срокларда «2025 елга һәм 2026, 2027 еллар планы чорына Тукай муниципаль районы бюджеты хакында» карар проекты буенча халык тыңлауларын әзерләргә һәм үткәрергә.

6. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны бюджет, салымнар һәм икътисадый сәясәт буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Муниципаль берәмлек Башлыгы
вазифаларын башкаручы,
Совет Рәисе урынбасары

Р.И. Закиров

СОВЕТ
ТУКАЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

пр. М. Джалиля, 46, г. Набережные Челны, 423800

ТУКАЙ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

М. Җәлил пр., 46, Яр Чаллы шәһәре, 423800

Телефон/факс (8552) 70-37-82, tukay@tatar.ru

11.11.2024 № 51/4

На №_________от_____________

# КАРАР

**«Тукай муниципаль районының муниципаль вазыйфаны даими нигездә биләүче затлары, муниципаль хезмәткәрләре хезмәтенә түләү системасы турында» «Тукай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Советының 2022 елның 29 декабрендәге 28/2 номерлы карарына үзгәрешләр һәм өстмәләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 24 апрелендәге 281 номерлы, 2018 елның 14 июнендәге 481 номерлы, 2018 елның 17 октябрендәге 940 номерлы, 2018 елның 29 декабрендәге 1320 номерлы, 2021 елның 17 ноябрендәге 1087 номерлы, 2021 елның 13 декабрендәге 1222 номерлы, 2022 елның 17 сентябрендәге 1015 номерлы, 2024 елның 30 апрелендәге 290 номерлы, 2024 елның 24 июнендәге 451 номерлы, 2024 елның 25 сентябрендәге 829 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән), район Уставы нигезендә муниципаль берәмлек Советы

## КАРАР БИРДЕ:

1. «Тукай муниципаль районының муниципаль вазыйфаны даими нигездә биләүче затлары, муниципаль хезмәткәрләре хезмәтенә түләү системасы турында» «Тукай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Советының 2022 елның 29 декабрендәге 28/2 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 2 пунктның 2 пунктчасында «13 323» саннарын «13 990» саннарына алыштырырга;

- 2 бүлекнең 2 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

«Муниципаль вазыйфаны даими нигездә биләүче зат хезмәтенә түләү айлык акчалата бүләкләү формасында башкарыла:

| Вазыйфа исеме | Айлык акчалата түләү күләме (сумнарда) |
|---|---|
| Муниципаль берәмлек Башлыгы | 42 541 |
| Муниципаль берәмлек Башлыгы урынбасары | 38 286 |
| Контроль-хисап палатасы рәисе | 38 286 |

»

4 бүлекнең 2 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

«Айлык акчалата кызыксындыру түләвен билгеләргә:

- муниципаль берәмлек Башлыгына 141 312 сум күләмендә;

- муниципаль берәмлек Башлыгы урынбасарына, контроль-хисап палатасы рәисенә 62 833 сум күләмендә.

Шул ук вакытта муниципаль берәмлек Башлыгының айлык җыелма акчалата түләүләре күләме Татарстан Республикасы министрына акчалата түләүләрнең айлык җыелма күләменән артмаска тиеш. Муниципаль берәмлек Башлыгы урынбасарына һәм контроль-хисап палатасы рәисенә айлык җыелма акчалата түләүләр күләме муниципаль берәмлек Башлыгының акчалата түләүләренең 0,55 айлык җыелма күләменнән артмаска тиеш.»;

4 бүлекнең 2 пунктында «13 323» саннарын «13 990» саннарына алыштырырга, «2024 елның 1 июленнән» сүзләрен «2025 елның 1 гыйнвареннән» сүзләренә алыштырырга;

4 бүлекнең 2 пункты 1 пунктчасын яңа редакциядә бәян итәргә:

«муниципаль хезмәтнең биләгән вазыйфасына бәйле рәвештә вазыйфаи оклад:

| **Вазыйфа исеме** | **Тапкырлау коэффициенты** (өченче төркем) | **Айлык вазыйфаи оклад күләме** (сум) |
|---|---|---|
| Башкарма комитет Җитәкчесе | 3,00 | 41 970 |
| Совет аппараты җитәкчесе | 2,77 | 38 753 |
| Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасары | 2,77 | 38 753 |
| Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары | 2,72 | 38 053 |
| Башка җирле үзидарә органы җитәкчесе (ФБП, Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы) | 2,71 | 37 913 |
| Башка җирле үзидарә органы җитәкчесе урынбасары | 2,46 | 34 416 |
| Мөстәкыйль бүлек башлыгы (мөдире) | 2,06 | 28 820 |
| Мөстәкыйль бүлек башлыгы (мөдире) урынбасары | 1,86 | 26 022 |
| Район Башлыгы ярдәмчесе | 1,7 | 23 783 |
| Баш белгеч | 1,52 | 21 265 |
| Әйдәүче белгеч | 1,43 | 20 006 |
| Башка җирле органының әйдәп баручы белгече | 1,43 | 20 006 |
| 1 категорияле , 2 категорияле белгеч, | 1,28 | 17 908 |

»

| | | |
|---|---|---|
| белгеч | | |

2. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнвареннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карарны районның рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны бюджет, салымнар һәм икътисадый сәясәт буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Муниципаль берәмлек Башлыгы
вазифаларын башкаручы,
Совет Рәисе урынбасары

Р.И. Закиров